Тормыш ямен мактаучы әдибә-Кояш Тимбикованың тормыш юлы һәм иҗаты буенча презентация.

# СҮНМӘС КОЯШЫБЫЗ

**Шатлыгым да – шул үзе, хәсрәтем дә - шул үзе:**
**Мин – татар кызы! Мин – татар кызы!**



Кояш Тимбикова
(1937-2004)

1937 елның 16 ноябрендә Чистай районы, Наратлы Елга авылында укытучы гаиләсендә туа. Иске Роман һәм Каргалы мәктәпләрендә 10 класс тәмамлаганнан соң Казан дәүләт университетында югары белем ала, аннары “Сөембикә”, “Казан утлары” журналларында секретарь булып эшли. Аның иҗат эше 1959 нчы елда башлана. “Сөлге булсын бүләгем”, “Агым уртасында”, “Кышкы талпыну”, “Ярлар биек” исемле һәм башка бик күп повесть, хикәяләре бар. 1969-1985нче еллар арасында К. Тимбикованың очерк, хикәя һәм повестьләре тупланган дистәгә якын китабы басылып чыкты. Аның аерым әсәрләре рус һәм башка телләргә тәрҗемә ителгән.



# К. Тимбикованың Татарстан китап нәшриятында басылып чыккан китаплары:

1. Зәңгәр күлмәк. 1969 ел.
2. Күңелләргә күләгә төшмәсен.1972 ел.
3. Якты йолдыз 1977 ел.
4. Кайгы белән шатлык янәшә.1979 ел.
5. Бәхет хакына.1981 ел
6. Тәңкәле тау. 1982 ел.
7. Кара юрга. 1983 ел.
8. Ярлар биек. 1985 ел.
9. Кышкы талпыну. 1987 ел.
10. Карәхмәт маҗаралары. 1989 ел
11. Тын бакчада. 1990 ел
12. Табылдык хатлар сере. 1992 ел.
13. Дулкын баласы. 1997 ел.
14. Песи, песи, пескәем. 1999 ел.
15. Кышкы былбыллар.2001 ел.
16. Өчәвенә - бер мәхәббәт (Бәян). 2003 ел.
17. Мин татар кызы (Җыр). 2003 ел.
18. Уртак яр. 2003 ел.

Якташыбыз татар зыялысы булган Кояш Тимбикова укучылар, халкыбыз күңелендә гади, гадел, юмарт, кояш кебек балкып торучы, сизгер күңелле, тормыш өчен җанын бирергә әзер булган кеше буларак кереп калды.



Флёра Тарханова



Фәния Хуҗахмәт



Мәдинә Маликова

# Безгә кунаклар килде



**Бертуган апасы Чәчәк.**



**Язучы Мәдинә Маликова, шагыйрә Флёра Тарханова**



“Мәдәни җомга” гәзите журналисты, “Татар календаре”н төзүче Фәния Хуҗахмәт дустын югалту хәсрәтеннән хушлашу сүзләрен әйтә.







Әлмира Әдиятуллина - “Мөслимә” газетасының мөхәррир урынбасары - “Сөембикә” журналы журналисты Мәдинә Маликова Кояш Тимбикова турында җылы сүзләрен әйтеп калдыра Иске Роман авылында.



Кояш Тимбикованы искә алу. Ул халык күңелендә мәңге сүнмәс кояш булып калды, үзенең әсәрләрендә, хикәя-повестьларында, халык күңелендә яшәячәк әле.

# Фотосурәтләрдә туган нигез, гаилә  җылысы, дуслык



Тимбиковлар йорты. 23.07.1962 ел



Тимбиковлар гаиләсе. Уңнан-әтисе Закир, кыз бала Ләлә, әни кеше Сания (итәгендә бәләкәй кыз Энже), олы ул Азат. 1929 ел.



Авторның әнисе ундa Сания һәм аның апасы Сәгъдия Җаббровалар. 1918 ел.



Чистайда Нәҗиб дәмелла мәрәсәсе шәкертләре. Алда (сулда) авторның әнисе Сания Җаббарова. 1915 ел.



Ленин орденлы укытучы Җәббаровлар нәселе. Сулдан уңга: Сания, Сәгъдия, Мирсияф, Мәрзия (бертуганнар). Аларның балалары: Кояш, Миләүшә, Ләбибә, Илсияр...



Энҗе һәм Чәчәкнең 1952 елның 6 июльдә алдырган рәсем. Казан шәһәре.


# Якташыбыз Кояш Тимбикованың
# әтисе – Закир Тимбиков, әнисе – Сания Тимбикова



# Монда синең күңел һәм кул җылың саклана.



Әнисеннән калган тегү машинасы



Язучының эш өстәле

# Экспонатлар җанга рухи байлык бирә.



Язучының патефоны



Язучының урын-җире





**Музей залыннан күренешләр**



# Сезгә карап хатирәләр яңара.



**Көнкүреш кирәк-яраклары**




Язучының милли киемнәре

# Синең исемен хезмәттәшләренә дәрәҗә булып кайта.



Кояш Тимбикованың әсәрләре мәңгелек.

Әдибәнең мирасы – үлемсез әсәрләре.







“Иске Роман – туган төбәгем, юксынудан өзелә үзәгем”
“Ерак чишмә - ямьле су буе, бөтенләйгә кайттым бу юлы”.





***Әйе, Кояш апа бөтенләйгә, үзенең балачагы, яшьлеге үткән Иске Романына мәңгелек йортына кайтты.***